КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 ноябрь г.Казань № 1245

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 март, 133 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында махсуслаштырылган оешма булып торучы коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында махсуслаштырылган оешма булып торучы коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү тәртибен раслау хакында» 2021 ел, 15 март, 133 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел,

29 гыйнвар, 69 нчы; 2022 ел, 30 июль, 736 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында махсуслаштырылган оешма булып торучы коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.1 пунктның өченче абзацында «30 нчы» сүзен «бишенче» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Республики Татарстан — А.В.Песошин